ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12.02.2021 г. Заинск № 82

**«Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычлар булу (булмау) турында салым түләүчеләргә мәгълүмат бирү эшен оештыру турында»**

Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе белән Зәй муниципаль районының мәгълүмати хезмәттәшлек турында килешүен гамәлгә ашыру максатларында, Зәй муниципаль районы Уставының 45 нче статьясына таянып, Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының структур бүлекчәләренә, муниципаль хезмәтләр күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткәндә, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурыч булу (булмау) хакында салым түләүчеләргә мәгълүмат бирү эшен оештырырга.
2. Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлегенә әлеге карар басылып чыкканнан соң өч эш көне эчендә Татарстан Республикасы дәүләт идарәсенең цифрлы үсеше, мәгълүмати технологияләр һәм элемтә министрлыгына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 елның 07 августындагы 674 номерлы карары белән расланган дәүләт хезмәтләре күрсәткәндә һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары дәүләт вазыйфаларын башкарганда ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибе нигезендә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне оештыруга заявка җибәрүне тәэмин итәргә
3. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны Зәй муниципаль районының http://zainsk.tatarstan.ru рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында урнаштырырга.
4. Әлеге карар басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.
5. Карар үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

П.А. Байрашев
3 22 73